**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге Некрасовка торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ**

«27» ноябрь 2024 ел № 16

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Некрасовка торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ**:**

2025 елда Яңа Иглай авыл җирлегенең Некрасовка торак пунктында яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан кала, 1 гр инвалидлардан тыш, 1000 сум күләмендә җыелган үзара салымны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу);

- Некрасовка торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- торак пункт территориясен төзекләндерү (Некрасовка авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) сатып алу)».

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х. Хәнәфиев

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы

вазыйфаларын башкаручы И.Х. Хәнәфиев